КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 август г.Казань № 693

Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын формалаштыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1.Кararга теркәлгән Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын формалаштыру тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 22 август, 693 нче
карары белән расланды

Карарга теркәлгән Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын формалаштыру тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын формалаштыру тәртибе «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә газга бәяләрне һәм аны транспортлау буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифларны дәүләт җайга салуы турында» 2000 ел, 29 декабрь, 1021 нче, «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлүче оешмалар тарафыннан газны транспортлауга тарифларга махсус өстәмәләр билгеләү тәртибе турында» 2001 ел, 3 май, 335 нче, «Капиталь төзелеш объектларын газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1314 нче, «Торак-коммуналь хуҗалык, сәнәгать һәм бүтән предприятеләрне газлаштыруның төбәкара һәм төбәк программаларын эшләү һәм тормышка ашыру тәртибе турында» 2016 ел, 10 сентябрь, 903 нче карарлары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлүче оешмалар тарафыннан газны транспортлауга тарифларга махсус өстәмәләр күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2011 ел, 21 июнь, 154-э/4 нче боерыгы нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын (алга таба – Чаралар планы) эшләгәндә һәм раслаганда Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган газ бүлүче оешмалар (алга таба – газ бүлүче оешма) арасында хезмәттәшлекнең эзлеклелеген һәм төп мәсьәләләрне билгели.

1.3. Чаралар планын формалаштыру үз эченә түбәндәгеләрне ала:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләреннән кергән заявкалар (шул исәптән физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен исәпкә алып), газ бүлүче оешмалар тәкъдимнәре анализы;

Чаралар планының өстенлекле объектларын тормышка ашыруга чыгымнарны беренче бәяләү.

1.4. Чаралар планы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

Татарстан Республикасын газлаштыру белән бәйле яңа газ бүлү системаларын, корылмаларын һәм аерым объектларны проектлау һәм төзү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектларын газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1314 нче карары белән расланган Капиталь төзелеш объектларын газ бүлү челтәрләренә

тоташтыру (технологик ялгау) кагыйдәләре нигезендә төзелгән тоташтыру (технологик ялгау) турында шартнамәләрне тормышка ашыру;

кулланучыларны ышанычлы һәм имин рәвештә газ белән тәэмин итү өчен гамәлдәге яңа газ бүлү системаларын, корылмаларын һәм аерым объектларны проектлау, төзекләндерү һәм яңарту, түбәндәгеләрне кертеп:

технологик закольцовкалар, күчереп куюлар, тоташтыргычлар, лупинглар кору;

автоматлаштырылган контроль системасын, технологик процесс белән идарә итүне оештыру;

бикләү, көйләү, үлчәү җайланмаларын һәм газ тотуны исәпләү әсбапларын урнаштыру һәм алыштыру.

1.5. Чаралар планы төзелеш объектлары исемлеген, төзелеш эшләре вакытын күрсәтеп, аларны финанслау күләмнәрен үз эченә ала.

1.6. Чаралар планында куелган максатларга ирешү максатында Чаралар планы буенча төзелеш өчен бүтән программалар белән эшләнгән проект-смета документларын, шулай ук Чаралар планы кысаларында эшләнгән проект-смета документларын бүтән программаларны тормышка ашыру өчен куллану рөхсәт ителә.

## 2. Чаралар планын эшләү, килештерү һәм раслау

2.1. Чаралар планы ел саен эшләнә.

2.2. Чаралар планы проекты Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты, газ бүлүче оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыру кысаларында, шулай ук кулланучыларга газны өзлексез транспортлауны тәэмин итү максатларында эшләнә.

2.3. Чаралар планы түбәндәге нигезләрдә формалаша:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән килештерелгән заявкалары (шул исәптән физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен исәпкә алып) һәм оешмаларның Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүнең расланган программалары кысаларында формалашкан, әлеге Тәртипкә кушымтага ярашлы форма буенча төзелгән тәкъдимнәре;

узган чордан күчкән һәм кабат Чаралар планына кушылган объектлар буенча кулланучыларга газны өзлексез транспортлау өлешендә газ бүлүче оешмалар тәкъдимнәре;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләренә капиталь төзелеш объектларын тоташтыру (технологик ялгау) кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1314 нче карары белән расланган Газ бүлү челтәрләренә капиталь төзелеш объектларын тоташтыру (технологик ялгау) кагыйдәләре нигезендә төзелгән тоташтыру турында шартнамәләрне тормышка ашыру максатларында төзү кирәк булган объектлар буенча газ бүлүче оешмалар тәкъдимнәре.

2.4. Газлаштыру объектларын (яңа төзелеш) Татарстан Республикасы Чаралар планы проектына кертү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (шул исәптән физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен исәпкә алып) һәм газ бүлүче оешмалар Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына түбәндәге документларны тапшыра:

газлаштыру объектларын әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге форма буенча Чаралар планы проектына кертү өчен гариза;

газ бүлү челтәрләренә тоташтыруның техник шартлары (техник мөмкинлек);

газлаштыру объектының билгеләнешенә бәйле муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты карары белән расланган территориянең генераль планы, территорияне планлаштыру проекты яки территорияне межалау планы;

трасса сайлауның беренче акты (кадастр саннары билгеләнгән җир кишәрлекләре урнашуның беренче схемасы);

төзелеш объектын эксплуатациягә кертүнең гамәлдәге һәм планлаштырылган вакыты турында муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты белешмәсе;

газлаштырылучы гамәлдәге һәм киләчәктәге кулланучылар саны турында муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты белешмәсе;

проект-смета документлары (булган очракта);

сәнәгать иминлеге һәм экология экспертизасы бәяләмәсе.

2.5. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләреннән кергән мәгълүматлар һәм документлар (шул исәптән физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен исәпкә алып), газ бүлүче оешмалар тәкъдимнәре нигезендә капиталь төзелеш объектын газ бүлү челтәрләренә тоташтыруның (технологик ялгауның) техник мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлгән газлаштыру объектларын Чаралар планы проектына кертү (үзгәрешләр кертү) яки Чаралар планы проектына мондый үзгәрешләр кертүдән мотивлаштырылган баш тарту турында карар кабул итә. Кергән мәгълүматлар һәм документларны карап тикшерү, алар буенча карар кабул итү тәртибен Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы билгели.

2.6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм газ бүлүче оешмалар тәкъдимнәре буенча финанслауның билгеләнгән күләме кысаларында Чаралар планының тупланма гаризаларына кертү өчен объектлар сайлап алу критерияләре түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы муниципаль районын газлаштыру дәрәҗәсе;

торак пунктны газлаштыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге (газлаштырыла торган торак пунктында потенциаль кулланучылар саны – кимендә 20 кеше), төзелешне тәмамлау һәм хокук билгеләүче (җир бүлү) һәм рөхсәт итүче документларны 2 календарь елга рәсмиләштерү мөмкинлеге;

поселокара һәм урам газ челтәрләрен өстенлекле үстерү;

билгеләнгән тәртиптә расланган уңай экспертиза бәяләмәләре белән проект-смета документлары булу;

кулланучыларны газ белән ышанчылы тәэмин итү максатында газ үткәргечләрнең ткәрү сәләтен арттыру кирәклеге;

газ белән тәэмин итү схемаларын тагын да рациональ үзгәртү, газ үткәргечләрдән файдалануның куркынычсызлыгын күтәрү максатында газ үткәргечләрне салу ысулын үзгәртү;

газ белән тәэмин итү объектларын авария хәленә китерергә мөмкин булган файдалануның уңайсыз шартлары;

газ бүлү технологик процесслары белән идарә итү системалары һәм газны исәпкә алу системаларының яңаларын, тагын да камил булганнарын гамәлгә кертү кирәклеге.

2.7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм газ бүлүче оешмаларның объектларны Чаралар планы проектына кертү өчен гаризаларын кабул итү Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан Чаралар планын формалаштырганга кадәр елның 15 февраленнән кабул ителә.

Төзелешнең һәр объекты буенча гаризалар һәм тиешле документлар аларны Чаралар планы проектына кертү өчен Чаралар планын формалаштырганга кадәр елның 15 маеннан соңга калмыйча Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына тапшырыла.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы гаризаны теркәгән көннән соң биш эш көне эчендә Чаралар планы проектына кертү өчен гаризаны карап тикшерүгә кабул итү хакында яки алга таба карап тикшерүдән баш тарту турында җавап бирә.

Чаралар планы проектына кертү өчен гаризаны карап тикшерүдән баш тарту өчен нигез булып әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмендә тапшырмау) тора.

Белешмәләрне тулы күләмдә тапшырмаган очракта гариза бирүче биш эш көне эчендә гаризаны тәгаенли, аларга җитмәгән документларны өсти һәм Чаралар планын формалаштырганга кадәр елның 1 июненнән соңга калмыйча Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына җибәрә.

Гариза бирүче тарафыннан Чаралар планын формалаштырганга кадәр елның 1 июненнән соң Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына җибәрелгән Чаралар планы проектына газлаштыру объектларын кертү турында тәкъдимнәр агымдагы елда карап тикшерелми, технологик тоташтыру объектларыннан тыш.

Агымдагы елның Чаралар планына кертелмәгән гариза бирүчеләр тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан әлеге Тәртиптә каралган вакытларда алдагы елларга Чаралар планы проектын формалаштырганда гариза бирүчеләр кабат мөрәҗәгать иткәндә объектлар буенча мәгълүмат актуальләштерелеп һәм кирәкле документлар теркәлеп карап тикшерелә.

2.8. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы Чаралар планын формалаштырганга кадәр елның 15 июненнән соңга калмыйча газ инфраструктурасының яңа объектларының җыелма исемлеген, газлаштыру объектлары буенча документларны һәм әлеге Тәртипкә кушымтага ярашлы гаризаларны теркәп, газ бүлүче оешмаларга проектлау һәм төзү чыгымнарының беренче хисаплау өчен җибәрә.

2.9. Газ бүлүче оешмалар Чаралар планы гамәлдә булганга кадәр елның 15 июленнән соңга калмыйча газ инфраструктурасының яңа объектларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү объектлар, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектларын газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1314 нче карары белән расланган Капиталь төзелеш объектларын газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) кагыйдәләре нигезендә төзелгән тоташтыру (технологик ялгау) турында шартнамәләрен тормышка ашыру максатларында төзү кирәк булган объектлар буенча эшләр бәясен беренче хисаплау нәтиҗәләрен, агымдагы елның Чаралар планыннан (Чаралар планы проекты) күчә торган объектларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына тапшыра.

2.10. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы газ бүлүче оешмалар тапшырган мәгълүматлар нигезендә Чаралар планы проектын эшли һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы белән килештерә, аны раслау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

2.11. Чаралар планы ел саен, агымдагы елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.